ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлегенең Янурыс авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

12 ноябрь 2025ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 12 ноябрендә үткәрелгән гражданнар җыенының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2026 елда үзара салым кертүгә, I төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан, шул исәптән катнашучы контрактчылардан (махсус хәрби операция барышында) һәм аларның гаилә әгъзаларенән тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

1) Су башнясын буяу, терәк кую, нигезне салу;
2) МТЗ-82 тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт өчен түләү, асылмалы җайланма сатып алу).
3) Брусчатка салу, Янурыс мәдәният йортының керү төркеменә бетон салу (төзелеш материаллары сатып алу, урнаштыру, хезмәт өчен килешү буенча түләү).
4) Янурыс т. п. һәйкәленә мемориаль такталар сатып алу, урнаштыру; (хезмәт өчен килешү буенча түләү);
5) Иске Әхмәт торак пункты юлларына вак таш түшәү (махсус техниканы арендалау, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, вак ташу һәм салу, грейдерлау);
6) Иске Әхмәт зираты өчен эш инвентаре сатып алу;
7) Хуҗасыз территорияләрдә, юл буенда эре агачларны һәм куакларны кисү (хезмәт өчен килешү буенча түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 263 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 201 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 201 катнашучы тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен __0____ катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Янурыс авыл жирлегенең Янурыс авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2026 елда 400 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан, шул исәптән катнашучы контрактчылардан (махсус хәрби операция барышында) һәм аларның гаилә әгъзаларенән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1) Су башнясын буяу, терәк кую, нигезне салу;
2) МТЗ-82 тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт өчен түләү, асылмалы җайланма сатып алу).
3) Брусчатка салу, Янурыс мәдәният йортының керү төркеменә бетон салу (төзелеш материаллары сатып алу, урнаштыру, хезмәт өчен килешү буенча түләү).
4) Янурыс т. п. һәйкәленә мемориаль такталар сатып алу, урнаштыру; (хезмәт өчен килешү буенча түләү);
5) Иске Әхмәт торак пункты юлларына вак таш түшәү (махсус техниканы арендалау, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, вак ташу һәм салу, грейдерлау);
6) Иске Әхмәт зираты өчен эш инвентаре сатып алу;
7) Хуҗасыз территорияләрдә, юл буенда эре агачларны һәм куакларны кисү (хезмәт өчен килешү буенча түләү).

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Янурыс авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына керту өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче А. Ә.Мөхәммәдиева